| | |
|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САРСАК-ОМГИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ САРСАК-УМГА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.03.2026 Сарсак-Умга авыл № 5

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Сарсак-Умга авыл җирлеге территориясендә киселә торган яшел утыртмаларның бәясен исәпләү һәм компенсация яшелләндерү методикасын раслау турында» 26.08.2025 елның 12 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Сарсак-Умга авыл җирлеге башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү турында

«Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Сарсак-Умга авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Сарсак-Умга авыл җирлеге территориясендә киселә торган яшел утыртмаларның бәясен исәпләү һәм компенсация яшелләндерү методикасын раслау турында» 26.08.2025 елның 12 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Сарсак-Умга авыл җирлеге башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.3 пунктының 4 абзацын төшереп калдырырга;

2) 1.3 пунктына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Яшел утыртмаларга хокуксыз зыян китергәндә яисә юкка чыгарганда зыянны исәпләү Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

3) 3.2 пунктының 2 абзацын төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Сарсак-Умга авыл җирлегенең мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштырырга (https://agryz.tatarstan.ru) һәм

Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкчесе Т.С.Николаева